КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 12 сентябрь г.Казань № 777

2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирелә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларга түләүсез кайнар ризык бирүне оештыруга һәм аның белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белем бирелә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларның кайнар ризык белән туклануының уртача кыйммәтен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирелә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларга түләүсез кайнар ризык бирүне оештыруга һәм аның белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны;

2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына башлангыч гомуми белем бирелә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларның кайнар ризык белән туклануының уртача кыйммәтен.

2. Җирле үзидарә органнарына 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына муниципаль мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирелә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларга түләүсез кайнар ризык бирүне оештыруга һәм аның белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны билгеләү буенча шундый ук карарлар кабул итүне тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирелә торган

мәгариф программалары буенча белем алучыларга түләүсез кайнар ризык бирүне оештыруга һәм аның белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белем бирелә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларның кайнар ризык белән туклануының уртача кыйммәтен раслау турында» 2023 ел, 4 сентябрь, 1066 нчы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 12 сентябрь, 777 нче
карары белән расланды

2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына
Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч
гомуми белем бирелә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларга
түләүсез кайнар ризык бирүне оештыруга һәм аның белән тәэмин итүгә
норматив чыгымнар

| Норматив чыгымнар исеме | Бер көнгә бер белем алучыга норматив чыгымнар күләме, сум | | |
|---|---|---|---|
| | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел |
| Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирелә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларга түләүсез кайнар ризык бирүне оештыруга һәм аның белән тәэмин итүгә норматив чыгымнар | 69,43 | 72,21 | 75,1 |

_______________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 12 сентябрь, 777 нче
карары белән расланды

2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына
башлангыч гомуми белем бирелә торган мәгариф программалары буенча
белем алучыларның кайнар ризык белән тукlануының
уртача кыйммәте

| Күрсәткеч исеме | Бер көнгә бер белем алучыга күрсәткеч зурлыгы, сум | | |
|---|---|---|---|
| | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел |
| Башлангыч гомуми белем бирелә торган мәгариф программалары буенча белем алучыларның кайнар ризык белән туклануының уртача кыйммәте | 69,43 | 72,21 | 75,1 |